СОВЕТ НОРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» сентябрь 2018 ел № 102

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Норма авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Норма авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2018 елның 14 сентябрендәге 98 номерлы Норма авыл җирлеге Советы карары, «Норма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2018 елның 14 сентябрендәге 19 номерлы Норма авыл җирлеге Башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы **карар бирде**:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2019 елда Норма авыл җирлегендә яшәүче 18 яше тулган, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 550 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- Кариле авылында: Дружба, Г. Тукай, С. Сәйдәшев, Г. Әшрәфҗанов урамнарындагы 5 һәм 7 номерлы йортлар арасындагы юлларны ремонтлау; Т. Миңнуллин, Х. Такташ, Төзүчеләр, Г. Исхакый урамнары буенча вак таш җәю; Лесная, Овражная урамнары буенча грунтлы вак таш җәю, янгынга каршы 2 гидрант урнаштыру һәм аларга комплектлау әйберләре сатып алу;

- Норма авылында: Лицей, М. Садри урамнарына вак таш җәю, М. Вахитов урамы буенча асфальт-бетон түшәмәле юлны ремонтлау, янгынга каршы 2 гидрант урнаштыру һәм аларга комплектлау әйберләре сатып алу, балалар мәйданчыгы төзү;

- Чапшар авылында: Х. Туфан, Ш. Усманов урамнары буенча юллардагы асфальт-бетон түшәмәгә чокыр һәм карталы ремонтлау;

- Кили авылында: агач кисү, Г. Тукай һәм Нариман урамнарын тоташтыручы җәяүлеләр күпере төзү, Г. Тукай урамы буенча вак таш җәю, янгынга каршы 2 гидрант урнаштыру һәм аларга комплектлау әйберләре сатып алу;

- Пүскән авылында: Ф. Кәрим урамында вак таш җәю, су белән тәэмин итү проектын эшләү;

- Нормабаш авылында: Г. Ибраһимов һәм Н. Баян урамнарын тоташтыручы күперне ремонтлау, Г. Ибраһимов урамы буенча шлагбаум урнаштыру, янгынга каршы 2 гидрант урнаштыру һәм аларга комплектлау әйберләре сатып алу;

- Норма һәм Кариле торак пунктлары өчен Норма авылында Бөек Ватан сугышы һәйкәле төзү.

**ЮК** **ӘЙЕ".**

3. Норма авыл җирлеге Советы карары нигезендә, аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җыелган акчаны экономияләү очрагында, экономияләнгән акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.

4. Әлеге карарны «Хезмәт» район газетасында һәм pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар аңа имза куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы А.И. Рамазанов